Әлмәт шәһәр Башкарма комитеты
карары

15 апрель 2020 ел. № 51

«Түбән Макткама ш.т.п М-4
микрорайонындагы 133 җир кишәрлекләренә
газүткәргечне тармакландыру» объекты өчен
территорияне планлаштыру проектын һәм
ызанлау проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планлаштыру структурасы элементларын билгеләү максатларында, «Татинвестгражданпроект»дәүләт унитар предприятиесенә мөрәҗәгать нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. "Татинвестгражданпроект" дәүләт унитар предприятиесенә үз акчалары хисабына «Түбән Макткама ш.т.п М-4 микрорайонындагы 133 җир кишәрлекләренә газүткәргечне тармакландыру» объекты өчен территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын эшләүгә керешергә тәкъдим итәргә (1 нче кушымта):

2. «Әлмәт муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне ызанлау проектын әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турында әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Вәлиев

Әлмәт шәһәр Башкарма
комитетының 2020 елның
«15» апрель  № 51 карарына
1 нче кушымта

Проектлаштыру территориясе чикләре




Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары                                        Д.В. Косарев